Гыйбадуллина, А. Т. Тормышым минем — шигырьләремдә : [шагыйрь Рәзиф Дәүләтов белән очрашу кичәсе сценарие] / А. Т. Гыйбадуллина // Ачык дәрес. - 2026. - № 5. - Б. 1-3.

Һәр дәрес нәтиҗәле булсын!

Ачык дәрес

(Ачык дәрес - Открытый урок)

2003 нче елның июленнән бирле чыга

Май № 5 (264)
2026

Укытучылар өчен методик ярдәмлек 12+

# Тормышым минем - шигырьләремдә!

Югары сыйныфта чаралар - 1- 6 бит

Югары сыйныфта дәресләр - 6 - 7 бит

Башлангыч сыйныфта дәресләр - 7 - 15 бит

Башлангыч сыйныфта чаралар - 15 - 24 бит

Балалар бакчасында - 24 - 48 бит

**Гыйбадуллина А.Т.**
Яр Чаллы шәһәре 12 нче китапханә

Шагыйрь, 2018 елдан “Ләйсән” әдәби иҗат берләшмәсе әгъзасы Рәзиф Әхмәтнәкый улы Дәүләтов белән очрашу кичәсе.

**Максат:** Шагыйрьнең иҗаты белән тирәнрәк таныштыру, аның шигырьләренең асылын аңлату. Укучыларда әдәбиятка, шигърияткә кызыксыну уяту.

Шагыйрь белән турыдан-туры аралашу мөмкинлеге тудыру, сораулар бирү аша фикер алышу. Милли мәдәнияткә, телгә һәм сәнгатькә мәхәббәт тәрбияләү. Яшь буында иҗади фикерләү сәләтен үстерү, аларны шигырь язарга рухландыру.

Рухи-әхлакый кыйммәтләрне ныгыту, матурлыкны тою хисен тәрбияләү.

Салмак көй астында сәхнәгә алып баручылар чыга.

**1 алып баручы:** Серле, бик серле бит ул шигърият дөньясы! Күңелендә шигырь уты кабынып, шигърият бакчасына аяк басарга теләгән кайсы гына җан иясе тылсымлы сүзләре белән шигърият капкасының ачылуын, бөтен барлыгы белән үзенең әлеге дөньяда калуын теләми икән! Шигърият шуңа да шигърият инде ул. Яктылыкка, яхшылыкка дәшүче, шәхесне дөнья ваклыкларыннан югары күтәрүче көч ул.

**2 алып баручы:** Хәерле көн! Исәнмесез, хөрмәтле укытучылар, шигырь яратучы укучылар! Һәр якның, һәр төбәкнең бик матур кешеләре бар. Төскә-биткә генә түгел, үзләренең күркәм эшләре, тоткан кыйблалары белән киләчәк буыннарга да үзләреннән тирән эз калдырган шәхесләр яши. Алар мактанып йөрмиләр, тыныч кына эшлиләр.

Бүген шушы матур, җыйнак залга без шәһәребездә яшәп иҗат итүче шагыйрь, 2018 елдан “Ләйсән” әдәби иҗат берләшмәсе әгъзасы Рәзиф Әхмәтнәкый улы Дәүләтов белән очрашуга җыелдык.

**1 укучы:** Һич кенә дә алдамыймын дуслар,
Сөйлим сезгә бары дөресен.
Ялган белән чынны бутамыйча,
Кушып әзрәк уен-көлкесен.
Әкияттәй матур безнең яклар,
Туган ягым Бикбау авылы.
Пугачев та чүттән адашмаган,
Үткән чакта безнең аркылы.
Ул болыннар дисәң, су буйлары,
Аръяктагы күлләр, таллыклар.
Ә шомырты, балан, карлыганы
Су өстендә уйный балыклар.

.... дип яза Рәзиф Дәүләтов “Һич кенә дә алдамыйм” дигән шигырендә. Рәзиф

Дәүләтов ( Рәзиф Дәүләт Бикбаулы) 1967 елның 7 гыйнварында Татарстан Республикасының Минзәлә районы Бикбау авылында туа. 1984 елда урта мәктәпне тәмамлап, Мәскәүдә М. С. Щепкин исемендәге югары театр уку йортында укый, 1988 елда драматик театр һәм кино актеры һөнәрен үзләштерә. Казанның Кәрим Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театрында эшли. Соңрак Чаллыда дәүләт драма театры актеры һәм режиссер буларак та хезмәт куя. Рәзиф, әңгәмәбезне менә шушы балачак, мәктәп елларын, югары уку йортында укыган, театрда эшләгән вакытларны искә төшерүдән башлыйк әле. (Кичә шагыйрь чыгышы белән дәвам итә)

**2 алып баручы:** Күктәге болытларны күзәткәндә, яшел чирәмле яланнарда аунаганда, гомумән, табигать кочагында йөзгәндә күңелдә хыял туа. Берәүләр аны хикәя, нәсер, әкият юлларына салса, икенчеләр әнә шул хыялый хисләрен шигъри тәлгәшләргә төрә.

**1 укучы:** "Яхшылыкка омтылам"
Күңелем белән һаман бала әле:
Мин ышанам бөтен юк-барга.
Әкиятләр укыйм шаклар катып,
Шундый җиңел мине алдарга.
Яңа елда Кыш Бабайны,
Шатланамын – алсам бүләген.
Көтеп торам кайчан чыгар диеп,
Тишегеннән безнең мөрҗәнең.
Су кергәндә карап, эзләп йөрим,
Тукай язган «суның анасын»,
Хыялланам бер күрергә, дип,
Башындагы алтын тарагын.
Урманнарда шүрәлеләр юллыйм,
Ышанамын төрле ырымга.
Урап узам хәтта башка җирдән
Кара мәче чыкса юлыма.
Бар нәрсәгә ышанганга ахры,
Башка юл юк минем ишегә.
Шуңа күрә бары изгелекләр,
Телимен мин һәрбер кешегә.
Аш атканга бары таш аткан, дип,
Әйтмәсеннәр безнең турыда.
Яхшылыклар эшләп калыйк әле
Дус-туганга, исән чагында!

**2 укучы:** "Эх, туарга яңадан!"
Эзләп йөрим яшьлектәге,
Мин калдырган эзләрне.
Күңелем белән һаман бала әле:
Мин ышанам бөтен юк-барга.
Әкиятләр укыйм шаклар катып,
Шундый җиңел мине алдарга.
Яңа елда Кыш Бабайны,
Шатланамын – алсам бүләген.
Көтеп торам кайчан чыгар диеп,
Тишегеннән безнең мөрҗәнең.
Су кергәндә карап, эзләп йөрим,
Тукай язган «суның анасын»,
Хыялланам бер күрергә, дип,
Башындагы алтын тарагын.
Урманнарда шүрәлеләр юллыйм,
Ышанамын төрле ырымга.
Урап узам хәтта башка җирдән
Кара мәче чыкса юлыма.
Бар нәрсәгә ышанганга ахры,
Башка юл юк минем ишегә.
Шуңа күрә бары изгелекләр,
Телимен мин һәрбер кешегә.
Аш атканга бары таш аткан, дип,
Әйтмәсеннәр безнең турыда.
Яхшылыклар эшләп калыйк әле
Дус-туганга, исән чагында!

**3 укучы:** "Эх, туарга яңадан!"
Эзләп йөрим яшьлектәге,
Мин калдырган эзләрне.
Беренче кат гашыйк булып,
Шашып йөргән хисләрне.
Табармын күк, әгәр кайтсам,
Бәхетле балачакка.
Юлын гына оныткanмын,
Борылыйм кай тарафка?
Хәтерлимен әтиемнең,
Мине күккә чөйгәнен.
Әниемнең бишек җырын,
Тыңлап йоклап киткәнем.
Иң бәхетле чакларымны,
Бик еш искә төшерәм.
Әткәемнең җыр сузганын,
Төшләремдә гел күрәм.
Эзләп йөрим, яшьнәп-күкрәп,
Узган яшьлек елларым.
Басылыр күк - әгәр тапсам,
Сагыну-сагышларым.
Табалмадым, эзләремне
Вакыт тузаны баскан...
Язгы аккан кар суыдай,
Эрегән, юкка чыккан.
Яшәр идем гомеремне,
Кире кайтып, кабаттан.
Белер идем яшәү тәмен,

Эх, туарга яңадан!

**1 алып баручы:** "... Шигъърият – мәңгелек балачак. Шагыйрь исә ак сакаллы бала. Шуңа шагыйрь күңелендә "кыш булмый вә кар яумый". Картаймый, шагыйрь замана керен эченә җыймый, каралмый, бала кебек күңеленә килгән уй – фикерне, нинди генә "куркыныч" булмасын, балачак эчкерсезлеге белән ярып сала. Бала да шагыйрь кебек пәйгамбәри заттан", - дип яза Айдар Хәлим.

**2 алып баручы:** Шигъърият шәхестән башлана. Ул шәхеснең иҗат җимеше. Иҗат – хыял, үз хыялыңны үзең куып җитәргә омтылу. Ә менә синең иҗат юлың ничек башланып китте? Беренче шигырьләрең ничә яшьтә язылды?

(Кичә шагыйрь чыгышы белән дәвам итә)

Кайтып киләм моңсу басу буйлап,
Чүп үләне баскан аны да.
Сукмакларда безнең эзләр калган -
Күңелләргә бигрәк авыр ла....
Авылыма керәм, күңел эзли
Яңа пешкән ипи исләрен.
Морҗалардан төтен чыкмый бүген,
Газ ягалар икән кичләрен.
Нихәл, газиз туган йортым минем?
Кайттым тагын синең яныңа.
Бикле ишек бары хыялымда
Ачыла да кебек, ябыла.
Әнкәм балкып каршы алыр төсле:
- Бик сагынган идем, кайттың бит!
Сусагансың, балам, чәйләп алыйк,
Менә, коймагыннан авыз ит!
Бусаганы атлыйм, сирәкләнгән
Зур авылның ялгыз өедер...
Күңелемә тыныч бер моң килә -
Бала чакның тынмас көедер... "Кайттым әле."

**2 алып баручы:** Рәзиф, шигырь ничек языла? Язу өчен илһам кайчан килә?

(Кичә шагыйрь чыгышы белән дәвам итә)

**1 алып баручы:** Шигырь язарга өйрәнеп буламы? Шигырь язу өчен шагыйрь булып туу кирәкме?

(Кичә шагыйрь чыгышы белән дәвам итә)

**2 алып баручы:** Шагыйрьләр бик күп төрле була. Алар арасында шигырь язучылар, шигырь ясаучылар, шигырь иҗат итүчеләр бар. Ә Рәзиф боларның берсенә дә охшамаган, ул бары тик күңелдән саркып чыккан уй – хисләрен кәгазьгә теркәп кенә бара кебек. Шуңа күрә алар табигый да, шуңа күрә алар болын чәчәкләре кебек тыйнак һәм нәзакәтле дә. Кеше гомере буена үз янәшәсендәге адәм балаларын аңларга, алар белән уртак тел табарга, аларга якынаерга теләп яши. Бу - теләсә-кайсы кешенең яшәү мәгънәсе. Әмма кеше күңелен, аның уй- хисләрен гади сүзләр белән генә берничек тә аңлатып булмый. Рәзиф Дәүләт Бикбаулының шигырьләрен укыган саен без аның кайгылары белән кайгыра, аның шатлыклары белән шатлана алабыз.

**1 алып баручы:** Рәзиф, үзеңнең иң яраткан шигырьләреңне укучыларга укуыңны сорыйбыз.

(Кичә шагыйрь чыгышы белән дәвам итә)

**2 алып баручы:** Безнең кунагыбыз әдәбиятка ашыкмыйча, әмма ныклы адымнар белән килә. Ул шәһәребез һәм республика битләрендә дөнья күргән "Эт оясы", "Очрашу", "Берәүнең дә келәте буш түгел яки чәйләрегез төмле булсын" кебек хикәяләре белән дә таныла.

Бездән, гади җир кешеләреннән нәрсә белән аерыла икән соң шагыйрьләр? Мөгаен, күңелләренең үтә нечкә, сизгер булуы белән, тынгы белмәс уйлары, әрнүләргә түзмәс җаннары беләндер. Үз йөрәкләрендә кайнаган хисләр өермәсен алар түкми-чәчми башкаларга җиткерә беләләр.

**1 алып баручы:** Кешегә тормыш бер генә бирелә. Рәзиф Дәүләтовка, тагын бер гомер бирсәләр, кем булыр иде? Бүгенге көндә яшь тамашачыларга нәрсә теләр идең?

**2 алып баручы:** Бүгенге җылы кичәбез ахырына якынлашты. Хөрмәтле кунагыбыз, сезнең белән булган матур мизгелләр күңелләребезгә күтәренке кәеф өстәде. Иҗат чишмәләрегез беркайчан да саекмасын, тагын да шулай безне куандырып, яңадан-яңа шигырьләрләрегез, китапларыгыз белән сөендереп торыгыз. Киләчәктә дә очрашулар булып торсын!

**1 алып баручы:** Игътибарыгыз өчен рәхмәт!